КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 декабрь г.Казань № 1507

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә файдаланылмый торган хайван каберлекләрен (биотермик чокырларны) юк итү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 6 май, 263 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә файдаланылмый торган хайван каберлекләрен (биотермик чокырларны) юк итү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 6 май, 263 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 3 март, 115 нче, 2021 ел, 17 июнь, 471 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Федераль законнар» сүзләрен «Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә файдаланылмый торган хайван каберлекләрен (биотермик чокырларны) юк итү тәртибенең 1.1 пунктында «Федераль законнар» сүзләрен «Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин